КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 5 сентябрь г.Казань № 759

Дәүләт өстәмә белем бирү учреждениеләре исемен алмаштыру турында

Спорт резервын әзерләү системасын формалаштыру, олимпия резервы статусы булган спорт әзерлеге оешмалары челтәрен, шулай ук сәләтле балаларны сайлап алу тәртибен җайга салу максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының бу карарга теркәлгән исемлек (1 нче кушымта) нигезендә дәүләт өстәмә белем бирү учреждениеләре исемен спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләре (алга таба – дәүләт учреждениеләре) итеп алмаштыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенең төп максаты – ул Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары әгъзаларын һәм спорт резервын әзерләү, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына:

дәүләт учреждениеләре функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

30 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләр кертергә:

дәүләт учреждениеләре уставларына;

дәүләт учреждениеләре өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәләренә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән берлектә, бу карарның 3 нче пунктында күрсәтелгән барлык чаралар тәгәлләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга спорт төрләре буенча спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 693 нче карарына аны әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә

үзгәрешләр кертү хакында карар әзерләргә һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

5. Дәүләт учреждениеләренең дәүләт йөкләмәләрен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлмәт, Лениногорск, Зеленодольск муниципаль районнарының, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына бу карарга теркәлгән исемлек (2 нче кушымта) нигезендә муниципаль өстәмә белем бирү учреждениеләре исемен спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы муниципаль учреждениеләр итеп алмаштыру буенча эш башкаруны тәкъдим итәргә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 5 сентябрь, 759 нчы
карарына 1 нче кушымта

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләре исемлеге

| Т/с | Дәүләт учреждениесенең үзгәрткәнгә кадәр булган исеме | Дәүләт учреждениесенең үзгәрткәннән соң исеме |
|---|---|---|
| 1. | «Спортның су төрләре буенча «Акватика» республика балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | «Спортның су төрләре буенча «Акватика» республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2. | «Батыр» республика махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «Батыр» республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе |
| 3. | «Динамо» республика махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «Динамо» республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе |
| 4. | «Стендка ату һәм пуля белән ату буенча республика махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | «Стендка ату һәм пуля белән ату буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 5. | «Фехтование буенча республика махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «Фехтование буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | «Тимераякта фигуралы шуу һәм шорт-трек буенча республика махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | «Тимераякта фигуралы шуу һәм шорт-трек буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 7. | «Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге Үзәк махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр шахмат мәктәбе» дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге Шахмат, шашка, го буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 5 сентябрь, 759 нчы
карарына 2 нче кушымта

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы муниципаль учреждениеләр исемлеге

| Т/с | Муниципаль районнар, муниципаль берәмлекләр | Муниципаль учреждениенең үзгәрткәнгә кадәр булган исеме | Муниципаль учреждениенең үзгәрткәннән соң исеме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Әлмәт муниципаль районы | «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 2. | Лениногорск муниципаль районы | Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче «Трамплиннан чаңгыда сикерү һәм чаңгыда ике төр ярыш буенча махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе | Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Трамплиннан чаңгыда сикерү һәм чаңгыда ике төр ярыш буенча олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 3. | Зеленодольск муниципаль районы | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 4 нче балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 4 нче спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 4. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге | «Олимпийский» махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «Олимпийский» олимпия резервы спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном учреждениесе |
| 5. | | «Витязь» балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «Витязь» спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном учреждениесе |
| 6. | | «Яр Чаллы» балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «Яр Чаллы» спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном учреждениесе |
| 7. | | «Көрәш буенча «Кэмпо» балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | «Көрәш буенча «Кэмпо» спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет учреждениесе |
| 8. | | «Дельфин» балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «Дельфин» спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном учреждениесе |
| 9. | | «11 нче махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «11 нче олимпия резервы спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 10. | | «12 нче махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе | «12 нче олимпия резервы спорт мәктәбе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном учреждениесе |
| 11. | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Вахитов районы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Вахитов районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 12. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Волейбол буенча «Юность» махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Волейбол буенча «Юность» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 13. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Спорт гимнастикасы һәм спорт акробатикасы буенча балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Спорт гимнастикасы һәм спорт акробатикасы буенча спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 14. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Җиңел атлетика буенча махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Җиңел атлетика буенча олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 15. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Нәфис гимнастика буенча «Грация» махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Нәфис гимнастика буенча «Грация» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 16. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Тасма» махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Тасма» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе |
| 17. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче Йөзү буенча «Дельта» олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Йөзү буенча «Дельта» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 18. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Су полосы буенча олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Су полосы буенча олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 19. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Нәфис гимнастика буенча «Приволжанка» махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Нәфис гимнастика буенча «Приволжанка» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 20. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Өстәл теннисы буенча махсус-лаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муници-паль бюджет мәгариф учреждениесе | Казан шәһәренең «Өстәл теннисы буенча олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 21. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Олимп» балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреж-дениесе | Казан шәһәренең «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 22. | | Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «Спектр» балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учрежд-ениесе | Казан шәһәренең «Спектр» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 23. | | Казан шәһәренең «Авиатор» комплексы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе | Казан шәһәренең «Авиатор» комплексы спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе |